ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01. 11. 2019 г. Заинск № 674

**«Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1089нчы карарына (29.06.2018) үзгәрешләр кертү турында**

“Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 853нче карарына (25.09.2018) нигезләнеп, Зәй муниципаль районы Уставының 45 маддәсенә таянып, Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. ”Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 1089 карарына (29.06.2018) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга: “Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Положение (5нче кушымта);

Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы гомумтармак эшче һөнәрләре һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләре,

мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, гомумтармак вазыйфаларының җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр хезмәтенә түләү шартлары турында Положение (6нчы кушымта);"

1.2. Түбәндәге эчтәлектәге 2.1. пункты белән тулыландырырга:

"2.1. Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәт хакын, әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгәнчә, яңача хезмәткә түләү шартларына күчкәнчегә кадәр гамәлдә булган системадагы (хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләмен, алар тарафыннан шул ук квалификация эшләрен башкаруны саклаган хәлдә) хезмәт хакыннан да ким булмаслык итеп билгеләргә."

1.3. Түбәндәге эчтәлектәге 3.1. пункты белән тулыландырырга:

"3.1. Зәй муниципаль районында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт учреждениеләре җитәкчеләренә хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килешү буенча:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартларын билгеләүче коллектив килешүләргә, үзара килешүләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләр кертергә;".

2. Әлеге карар 2019 елның 1 октябреннән гамәлгә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында, муниципаль районның рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**